ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

«01» ноябрь 2022 ел № 111-р

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - вакантлы вазыйфаны биләүгә конкурс игълан итү турында

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының вакантлы вазыйфаларны биләүгә конкурс үткәрү, аттестация буенча бердәм комиссияләре турында, сыйныф чиннары бирү турында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарында һәм алар буйсынуындагы муниципаль учреждениеләрдә эш стажын билгеләү һәм аларның тиешле еллар эшләгәнен исәпләү буенча карар чыгару буенча карар чыгару турында» 13.07.2022 елның 18-5 номерлы карары нигезендә:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс игълан итәргә.

2. Конкурска документларны 03.11.2022 елнының 8.00 сәгатьтән 22.11.2022 елнының 16.00 сәгатенә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул итәргә: Әгерҗе шәһәре, Гагарин урамы 13, 11 нче кабинет (Администрация бинасы), көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, тел. 2-38-71.

3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарында һәм алар буйсынуындагы муниципаль учреждениеләрдә вакантлы вазыйфа биләүгә кандидатларны конкурс үткәрү буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының бердәм конкурс комиссиясе 23.11.2022 елны вакантлы вазыйфа биләүгә кандидатлар сайлап алуны үткәрү буенча конкурс үткәрергә.

4. Әлеге боерыкны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru) вакытлы матбугат басмасында - «Татмедиа» АҖ филиалының Әгерҗе районы «Әгерҗе хәбәрләре» газетасында бастырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Җитәкче вазифаларын башкаручы** **Р. Р. Шәрипов**